ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)

**IV чакырылышның чираттагы утырыш**
**КАРАРЫ**

**№ 14 Кәрәкәшле ав. 22 апрель 2025 ел**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары
вәкаләтләрен вакытыннан
алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлге Уставының 50 статьясындагы 5 өлеше, 51 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы урынбасары З.Ә.Мәрдadminованың 22.04.2025 елда үз теләге белән отставкага китүе турындагы гаризасына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы урынбасары Мәрданова Зөлфия Әнфәс кызының вәкаләтләрен, үз теләге белән отставкага китү сәбәпле, 2025 елның 23 апреленнән вакытыннан алда туктатырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» http://jutaza.tatarstan.ru порталына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында: Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 19 йорт (Кәрәкәшле авыл мәдәният йорты); Салкын Чишмә авылы, Фрунзе урамы, 4а йорт (Салкын Чишмә авыл клубы); Урал авылы, Урал урамы, 3а йорт (күпфункцияле үзәк бинасы); Ак Чишмә авылы 24а номерлы йорт янында урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге

башлыгы урынбасары: З.Ә. Мәрданова